**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**САРМАН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**

**Сарман авыл жирлеге**
**423350 Сарман авылы, Ленин ур.,52**
**тел.: 2-43-67, 2-45-38**
**E - mail: sar.sar@tatar.ru**
ИНН/КПП 1636005461/163601001

**Сармановское сельское поселение**
**САРМАНОВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
**423350 с. Сарманово, ул.Ленина, 52**
**тел.: 2-43-67, 2-45-38**
**E – mail: sar.sar@tatar.ru**
ИНН/КПП 1636005461/163601001

11 ноября 2016г. № 15

Җәмәгать тыңлауларын билгеләү турында

Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Сарман авыл җирлегендә яшәүчеләрнең фикерен һәм мәнфәгатьләрен ачыклау һәм исәпкә алу максатларында, Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы, Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы «Сарман авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең җир биләмәләреннән файдалану һәм төзелеш Кагыйдәләре, Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Советының 12.02.2013 ел, № 4 карары белән расланган җир кишәрлеген шәһәр төзелеше зонасын үзгәртү мәсьәләсе буенча Сарман муниципаль районы Сарман авыл җирлеге Советының 19 нчы маддәсенә таянып, Сарман муниципаль районы «Сарман авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 19 ст. 7 п. нигезендә

Карар бирәм:

1. Ачык тыңлаулар билгеләү:

Җир кишәрлекләрен шәһәр төзелеше зоналаштыруны үзгәртү буенча Сарман авылы, С.Рафиков урамы, 25 адресы буенча урнашкан 16:36:020301:683 кадастр номерлы, мәйданы 500 кв. м. «гомуми файдаланудагы җирләр» төреннән «башка элемтә объектларын урнаштыру» төренә күчерү.

2. Билгеләү:

- ачык тыңлауларны оештыручы-Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Сарман авыл җирлеге башкарма комитеты;

- ачык тыңлаулар үткәрү вакыты-01.12.2016 ел 15.00 сәгатьтә;

үткәрү урыны-киноучреждение бинасында конференц-зал (адресы: Сарман авылы, Ленин ур., 28);

– фикер алышына торган мәсьәлә буенча язмача тәкъдимнәр һәм искәрмәләр кертелә торган адрес: Сарман авылы, Ленин урамы, 52, Сарман авыл җирлеге башкарма комитеты (эш көннәрендә 8.00 дән 16.00 сәгатькә кадәр).

3. Әлеге карарны махсус мәгълүмат стендларында бастырып чыгарырга һәм «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында» PRAVO.TATARSTAN.RU) Татарстан Республикасы «Сарман муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында урнаштырырга. 2016 елның 1 декабреннән дә соңга калмыйча хәбәр ителә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотам.

Сарман авыл җирлеге
Башкарма комитет җитәкчесе Хәсәнов И. Я.